КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 апрель г.Казань № 313

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче, 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 10 апрель, 272 нче, 2020 ел, 13 апрель, 280 нче, 2020 ел, 18 апрель, 306 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$10^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^1$. Түбәндәгеләргә йөкләргә:

2020 елның 14 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр түбәндәге гражданнарга 14 календарь көн дәвамында өйдә үзизоляцияләүне тәэмин итәргә;

Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән килгән (кайткан);

Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән килгән (кайткан) гражданнар белән изоляцияне тәэмин итү чорында бергә яшәүче;

2020 елның 23 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр түбәндәге гражданнарга 14 календарь көн дәвамында өйдә үзизоляцияләүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе субъектлары территорияләреннән килгән (кайткан);

Россия Федерациясе субъектлары территорияләреннән килгән (кайткан) гражданнар белән изоляцияне тәэмин итү чорында бергә яшәүче.

Әлеге пунктта күрсәтелгән затлар, беренче респиратор симптомнар барлыкка килгәндә, кичекмәстән, медицина оешмаларына бармыйча, өйдә медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләр түбәндәгеләргә кагылмый:

йөкләрне, пассажирларны һәм багажны халыкара, төбәкара ташуларны гамәлгә ашыручы затлар;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә эшчәнлеге туктатылмаган (чикләнмәгән) оешмаларның Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче һәм әлеге оешмаларда, шул исәптән вахта ысулы белән эшләүче хезмәткәрләре. Күрсәтелгән оешмаларга, Татарстан Республикасы территориясеннән читтә яшәүче хезмәткәрләрне дистанцион эш формасына күчерү мөмкин булмаганда, аларның эшен күбесенчә вахта методы белән оештырырга һәм әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итеп, Татарстан Республикасы территориясендә компактлы аерым яшәү рәвеше алып бару мөмкинлеген оештырырга;

Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән, дәүләт оборона заказын үтәүне тәэмин итүче оешмалар өчен эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның хезмәткәрләре, мондый хезмәткәрләрнең, әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итеп, Татарстан Республикасы территориясендә компактлы аерым яшәү рәвешен оештыру шартларында.»;

түбәндәге эчтәлекле $10^2$ пункт өстәргә:

«$10^2$. 2020 елның 14 преленнән Татарстан Республикасына чит дәүләтләр территорияләреннән килгән (кайткан) затларга карата алар килеп җиткәннән соң 14 календарь көн дәвамына обсерватор шартларында аларны изоляцияләү һәм медицина күзәтүе тәэмин ителә.»;

11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның 23 апреленнән башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр 22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр ваклап сату объектларының эшен, даруханәләр һәм даруханә пунктларыннан тыш.».

2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин